# «ЙОЛДЫЗЛАРГА ҮРЕЛЕП ЯШӘ»
## Кадрия Наил
## иҗатына бер караш

Күңелдәге хисләремә карап,
Шигырьләрем туа төрлечә:
Кайсы елап туа, ә кайсысы
Җырлый-җырлый туа – үземчә!
(«Сәбәпчеләр»)

Кадрия Наилнең шигырь юллары тууга сәбәпчеләре байтак. Табигатьнең яшәргән мизгеле дә, зифа буйлы каеннары да, үләндәге энҗе чыклар да, ялгызлыктан йөрәге елаган мизгелләр дә. Менә инде иҗат юлына баскан 2007 еллары да шактый еракта калган. Шәхси тормышындагы уңай, тискәре дә булган үзгәрешләр аны кулыннан каләмен төшермичә яшәтә. Кадрия – шәһәребездә даими эшләп килүче «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсе әгъзасы. Вакытлы матбугат битләрендә «Таң йолдызы», «Якты юл», «Шәһри Чаллы», «Алабуга нуры», «Мәдәни җомга» газеталары, «Сөембикә», «Мәйдан» журналларында аның иҗат шытымнары еш басылалар. Тәүге шигъри җыентыгы «Агыла күңелем моңнары» исеме белән 2008 елда дөнья күргән булса, бүген ул – тугыз китап авторы. Лаеклы ялга чыгып, балалар-оныклар янәшәсендә, Алабуга шәһәрендә яши.

Кадрия Наил (Кадрия Наил кызы Хәлилова) тумышы белән Актаныш районы Зөбәер авылыннан. 1951 елның 1 нче августында гаиләдә өченче бала булып дөньяга килә, балачак һәм үсмер еллары Мөслим районының Симәк авылында үтә. Авыл мәктәбенең сигезенче сыйныфын тәмамлаган кыз, Бөгелмә медицина училищесына юл тота һәм гомерен шәфкать туташы хезмәтенә багышлый.

Ә иҗатка килгәндә, ул яшьтән үк серле, моңлы бала була. Иҗат – ул аның күңел халәте! Яратуы, хөрмәте, рәхмәте дә шигырь юлларына салынган.

Читтә гомер кичерсә дә, ул гел туган нигез, туган авылы кешеләре белән горурланып яши. Туган якларга булган хисләрен, хөрмәтен, сагынуын шигъри юллар белән аңлатырга ашыга:

Ярый әле, авылым бар –
Саклаучы нигез ташын.
Арган чакларымда кайтып,
Куярга газиз башым.
*(«Тормышым бизәүчеләр»)*

Иҗатында төп мотивларның берсе булып, әти-әни хакы, туганлык юлларының тыгыз, мәхәббәт җепләре белән бер-берсенә бәйләнеп баруы ярылып ята. Туганнар, балалар, оныклар белән горурланып, алар өчен сөенеп яши автор.

Алтынга тиң туганнар бар –

Иңне-иңгә терәргә,

яисә:

Оныкларым гөлләр кебек
Бизи минем тормышны.

*(«Тормышым бизәүчеләр»)*

Ул кадерле әти-әнисеннән калган һәрбер әйбер өчен җан атып яши: гөл, шәл, дисбе, чулпылар аның өчен бәһале, ул аларны бик хөрмәт итеп саклый, үзенең шигырьләрендә дә аларга булган мөнәсәбәтен чагылдыра:

Әнкәм рухы булган шәлне саклыйм
Бик кадерләп төреп сандыкта.

*(«Мамык шәлдә әнкәй исләре»)*

Мамык шәлдә ул аңа күңеленең назын тойса, гөлләр аңа яшәр өчен көч бирә, ул да, үз чиратында, аларга яшәү, чәчәк атар өчен сулар сибергә онытмый:

Газиз әнкәмнең гөлләрен
Назлап кына үстерәм.
Алар миңа, мин аларга
Яшәр өчен көч бирәм.

*(«Серем гөлләргә сөйлим»)*

Әти-әнисенә дөньялыкта әйтергә өлгермәгән сүзләрен, аларның матур тормыш юллары кичүенә сөенеп, шигырь юллары тудыра. Инде вакытлар үтсә дә маяк булып яшәүләренә һәрдаим чиксез сөенеп, аларның рухына, шигъри юлларга салып, дога кылырга да җаен таба:

Фани дөньялардан киткәннәргә
Дога кылыйк иң чын күңелдән.

*(«Киткәннәргә дога кылыйк»)*

Амин, шулай булсын, укыган һәрбер догасы барып ирешсен. Кадрия Наил ике бала анасы, өч онык әбисе буларак, үзен өлкән буын вәкиле итеп санап, шигырь юллары белән үз вәгазен ишеттерергә дә мөмкинчелек эзли:

Балаларның балалары хәтта
Онытмасын изге тамырын.
Бездән соң да өзми сакласыннар
Буыннарның нәсел чылбырын.

*(«Нәсел чылбыры»)*

Ул, бер шигырьдән икенчесенә күчеп, әти-әнисен искә алып, хәтерендә яңартып яши, иҗат итә.

Әле дә җитми миңа карашлары,
Күңел белән һаман сабыймын.

*(«Күңел һаман сабый»)*

дип яза ул, әтиле-әниле елларын кире кайтарасы килеп. Ләкин юк... Булмый! Бөек Ватан сугышы ветераны, Ленин ордены кавалеры Наил абый, күп еллар колхоз рәисе булып эшли. Әтисе, аның кылган эшләре белән горурланып, авылдашлары, якташлары исеменнән дә аңа рәхмәт сүзләре җиткерә Кадрия. Алар «Җәй көнендә җиләккә дип баргач», «Ветераннар» сүзен ишетүгә», «Әткәм белән әнкәм куллары» һәм башка бик күп шигырьләрдә урын алганнар. Әнисе Зәнфирә апа өчен язылган шигырьләр дә шактый: «Әнкәм дисбесе», «Бәхет ачкычлары», «Кичер, әнкәй», «Ник ашыктың, әнкәй..», «Серем сөйлим гөлләргә», «Мамык шәл», «Иң татлы сүз», «Әниләргә гомер телик».

Сезнең кулларга килеп кергән «Бәхет нуры» җыентыгының башыннан ахырына кадәр ак, яшел төсмерләр сибеп, яшьлек, тәүге хисләр, мәхәббәт мизгелләренә багышланган шигырьләр озата бара. Тормышта, авторның өмет чыганагы булып, яраткан кешесе тора. Ул һәркемне, сөю утында яратып, яратылып яшәргә өнди, алай гына да түгел, һәрбарчабызны шуңа этәрә кебек.

Бикле күңелләрнең биген
Бәхет нурлары ачсын.
Сөю керсен йөрәкләргә,
Дөнья ямьнәре артсын.

*(«Бәхет нуры»)*

Ләкин мәхәббәт булган җирдә хыянәт, кавышу, аерылулар да хөкем сөрә.

Авырлыклар килә, китә,
Алмашка килә шатлык.
Авырлыклардан уфтанмыйм,
Дәвалаучысы – вакыт.

*(«Үз язмышым»)*

Шулай ук җыентыкның бер бүлегендә туганнар, дуслар, каләмдәшләр, хезмәттәшләргә багышланган мәкаләләр урын алган. Һәр язма үзенә күрә кызыклы, игътибарга лаек. Авторның бик күп кенә шигырьләре («Кичер, әнкәй», «Күзләр искә төшерде», «Җаным сине көткән», «Көтмәгәндә», «Сөепләр калыйм әле», «Сөюләрне сыңар чак» һ.б.), шәһәребез композиторлары Рубис Зарипов, Владимир Мироваев, Илдус Салахов, Мәҗит Зайнуллин, Валерий Әхмәтшин тарафыннан көйгә салынган.

Кадрия Наил Ходай биргән язмышына рәхмәтле. Яшәве, кулында каләм уйната алуы белән бәхетле ул.

Күңел күгем гел кояшлы,
Кояшсыз көннәр сирәк.
Дөнья матур, яшәү рәхәт,
Тынмасын гына йөрәк.

*(«Тынмасын гына йөрәк»)*

Кадерле шигъри җанлы укучылар! Әлеге китапта һәркем үзенә кирәкле шигырь юлларына тап булыр.

Язмышымнан зарланмыйча,
Хыялларга күмелеп,
Күзләремә кереп барам,
Йолдызларга үрелеп.

*(«Үз язмышым»)*

Кадрия, үзең язганча, гомер күзләренә кергәнеңне сизми, йолдызларга үрелеп яшә, серле шигырь дөньясында иҗат ит!